КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 июнь г.Казань № 742

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча спорт чараларын - Россия беренчелеген, «Балалар лигасы» республика ярышларын, һәвәскәр спортчылар арасында ярышлар уздырганда кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларындаТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ :

1. Казансу елгасында Кремль дамбасыннан «Милленимум» күперенә кадәр участокта 2023 елның 8 июлендә 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, 2023 елның 9 июлендә 7.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр аз үлчәмле судноларны, шул исәптән гидроциклларны, байдаркаларны, ишүле көймәләрне, шулай ук җилкәнле, йөрүче, спорт судноларын куллануны тыюны (алга таба - тыю) билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

тыюны үтәү максатларында күрсәтелгән участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

тыю турында халыкка хәбәр итү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан

Республикасы буенча Баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Тыюның триатлон буенча спорт ярышларын әзерләү, уздыру һәм аларда катнашу өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмавын билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2017 ел, 28 март, 196 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2017 ел, 28 март, 196 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 23 июнь, 421 нче;

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә IRONSTAR триатлон буенча халыкара ярышлар үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2017 ел, 3 август, 549 нчы;

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2018 ел, 12 апрель, 233 нче;

«Триатлон буенча ярышлар, Red Bull Air Race авиаузышлар этабын һәм «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2018 ел, 3 июль, 542 нче;

«Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2019 ел, 25 апрель, 342 нче;

“2019 елгы Red Bull Air Race авиаузышлар дөнья чемпионаты этабын һәм TIMERMAN триатлон буенча ярышлар үткәргәндә Татарстан Республикасы территориясендә су объектларыннан файдалану турында” 2019 ел, 01 июнь, 458 нче;

«Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә Казан шәһәре чикләрендәге су объектларыннан файдалану турында» 2019 ел, 25 июль, 620 нче;

«Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә Казан шәһәре чикләрендәге су объектларыннан файдалану турында» 2020 ел, 17 июль, 602 нче;

«2020 елда «Илкүләм җилкәнле лиганың II этабы» җилкәнле спорт ярышларын һәм «Чайка» пассажир судносын тәкъдир итү чарасын үткәргәндә Татарстан Республикасы территориясендә су объектларыннан файдалану турында» 2020 ел, 24 август, 725 нче;

«Казан шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2021 ел, 1 июль, 526 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре һәм Зеденодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2021 ел, 01 июль, 526 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 ел, 06 август, 687 нче;

«Татарстан Республикасы көненә һәм Казан шәһәре көненә багышланган бәйрәм салюты уздырганда су объектларыннан файдалану турында» 2021 ел, 18 август, 740 нчы;

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатын уздырганда су объектларыннан файдалану турында» 2022 ел, 8 июнь, 539 нчы;

«Казан шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2022» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2022 ел, 11 июль, 666 нчы;

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында» 2022 ел, 4 август, 759 нчы;

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча (дисциплина – акватлон) Россия чемпионатын һәм беренчелеген уздырганда су объектларыннан файдалану турында» 2022 ел, 22 август, 885 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин